**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 апрель № 212

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында телевидение һәм радио тапшыруын үстерү һәм санлы технологияләргә күчү буенча республика комиссиясе турында» 2006 ел, 6 сентябрь, 451 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында телевидение һәм радио тапшыруын үстерү һәм санлы технологияләргә күчү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында телевидение һәм радио тапшыруын үстерү һәм санлы технологияләргә күчү буенча республика комиссиясе турында» 2006 ел, 6 сентябрь, 451 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2008 ел, 28 апрель, 278 нче; 2010 ел, 23 ноябрь, 928 нче; 2011 ел, 4 апрель, 248 нче; 2012 ел, 7 август, 671 нче; 2012 ел, 2 октябрь, 819 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында телевидение һәм радио тапшыруын үстерү һәм санлы технологияләргә күчү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан А.Н.Бобровны, А.И.Җиһаншинны, Н.Г.Мәһдиевне, Е.Ю.Паткинаны, И.Җ.Миңнеәхмәтовны, А.Р.Хәйруллинны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм іоммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасын буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Борис Николаевич Разиновны (килешү буенча);

Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасы буенча территориаль идарәсе җитәкчесе Гөлнара Илдус кызы Сергееваны (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы Айрат Рафинант улы Мостафинны;

Татарстан Республикасының урман хужалыгы министры Алмас Әмин улы Нәзировны;

Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Олег Александрович Степущенконы;

«Татмедиа» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры Фәрит Илдус улы Шаһиәхмәтовны (килешү буенча);

Айрат Ринат улы Зарипов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары»;

Владимир Николаевич Якимов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия телевидение һәм радио тапшырулары челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесенең «Татарстан Республикасы радиотелевидение тапшыруы үзәге» филиалы директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\212.doc